**Татарстан Республикасы**
**Тукай муниципаль районы**
**Калмия авыл җирлеге составына керүче**
**Калмия авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

# КАРАР

28 ноябрь, 2021 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 28 ноябрендә узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән түбәндәге мәсьәлә буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2022 елда яшәү урыны буенча Калмия авыл җирлеге Калмия авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 ( биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- 1. Калмия авылы территориясенә балалар мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру.

2. Калмия авылы территориясендэге спорт мәйданчынына коймалар сатып алу һәм урнаштыру.

3.Калмия авылы территориясендәге спорт мәйданчыгын каплау өчен җайланма (сатып алу һәм урнаштыру)

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 302 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 154 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 154 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Калмия авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2022 елда яшәү урыны буенча Калмия авыл җирлеге Калмия авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум

күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- Калмия авылы территориясенә балалар мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру.

- Калмия авылы территориясендәге спорт мәйданчынына коймалар сатып алу һәм урнаштыру.

- Калмия авылы территориясендәге спорт мәйданчыгын каплау өчен җайланма (сатып алу һәм урнаштыру)

3. Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Калмия авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Калмия авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Калмия авыл җирлеге Башлыгы Р. Ә.Гарипов